ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР ПУЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423730, Пучы авылы,
Киров ур., 2А нче йорт.
Тел. 3-44-51
e–mail: pois.akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ПОИСЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423730, с. Поисево
ул. Кирова, дом 2А.Тел. 3-44-51
e–mail: pois.akt@yandex.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**30 сентября 2024 года** **№ 19**

Актаныш муниципаль районы Пучы авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 24 маендагы 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Пучы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Актанышбаш авыл җирлеге советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Пучы авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 24 маендагы 11 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

"1,2% нисбәттә Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән 1000 квадрат метрдан артык гомуми мәйданы булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар).».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштырырга.

Актаныш муниципаль районы
Пучы авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Ф.Ф. Файзуллин